# *Балаларның бәйләнешле сөйләм телен үстерүдә татар халык уеннарының роле.*

**Казан шәһәре Мәскәү районы 395 нче номерлы балалар бакчасы.**
**Татар теленә өйрәтүче тәрбияче**
**Заһидуллина Регина Наил кызы**

***Уйныйк,***

***Сөеник,***

***Көлик***

***Уйныйк, сөеник, көлик!***
***Дәртле, җанлы, без күңелле,***
***Безгә ямьле Җир йөзе,***
***Безгә карап елмая***
***Күкнең кояш, ай, йолдызы!***

***(С. Миңлекәй)***

**Проектның төре**: танып белү, бәйләнешле сөйләм телен үстерү.

**Проектның дәвамлылыгы**: бер ел.

- **Максат:** Татар халык уеннары аркылы балаларның бәйләнешле сөйләм телен үстерү.
- **Бурычлар:** - Татар халык уеннарына кызыксыну уяту

  - Балаларга физик һәм эстетик тәрбия бирү

  - Балаларга татар халык уеннарын мөстәкыйль уйнарага өйрәтү.

**Проектның этаплары:**

Әзерлек этабы

Проектның темасын сайлау

Проблема кую

Проект буенча материал җыю

Татар халык уеннары картотекасы ясау

Әти-әниләр почмагын тулыландыру

Әти-әниләрне татар халык уеннары белән таныштыру.

Татар халык уеннарына кирәк булган атрибутларны булдыру

# Төп этап:

Балаларны татар халык уеннары белән таныштыру

Уен барышын сөйләү, аңлату

Сүзле уеннарда шигырьләр, җырларны өйрәтү

Шөгыльләрдә  сүзле уеннарны кулланып

физкультминуткалар үткәрү

Халык иҗат иткән уенчыклар белән танышу.

Татар халык уеннарын уйнау.

Йомгаклау: “Күңелле Сабантуй уеннары”

# Перспектив-тематик план

| № | Уенның исеме | Уенның төрләре | Балаларның яшь үзенчәлеге | Тәрбияче белән балаларның бердәм эшчәнлеге | Балаларның мөстәкыйль эшчәнлеге | Үткәрелү вакыты |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 1. | Песи һәм тычканнар | Ярыш | 3-4 яшь (кечкенәләр төркеме) | Песи ролен тәрбияче башкара, балалар тычканнар булалар | Балаларның мөстәкыйль рәвештә үз урыннарына йөгерүләре | Сентябрь октябрь |
| 2. | Йорт куяннары | Шуышулы | 3-4 яшь (кечкенәләр төркеме | Тәрбияче балаларга команда бирә | Балалар шуышып “өйләренә” кайталар | Ноябрь декабрь |
| 3. | Хәйләкәр төлке | Сикерүле | 4-5 яшь (уртанчылар төркеме) | Балаларда җитезлек, өлгерлек, игътибарлылык сыйфатларын булдыру | Хайваннарны танып белү, тиз йөгерү, сикерү күнекмәләрен булдыру | Октябрь ноябрь |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| **4.** | Ватык телефон | Аз хәрәкәтле уен | 4-5 яшь (уртанчылар төркеме) | Балаларга бер берсе белән диалог төзергә өйрәтү | Игътибарлылык сәләтләрен үстерү | Июнь, июль айлары |
| 5. | Зәңгәр чәчәк | Җырлы биюле уен. | 4-5яшь (уртанчылар төркеме) | Балаларга татарча шигырь юлларына салынган сүзләрне өйрәтү | Мөстәкыйльбию һәм җырлау | Ноябрь, декабрь |
| 6. | Казлар, аккошлар | Йөгерүле | 4-5яшь (уртанчылар төркеме) | Уен барышында сүзләрне рольләргә бүлеп өйрәтү | Балалар ролле уеннарны үзләре башкаралар | Июль август |
| 7. | Йөзек салыш | Аз хәрәкәтле | 5-6 яшь (зурлар төркеме) | Балалар бер-берсенә сорау биреп аралашалар. | Мөстәкыйль аралашалар | Март, апрель |
| 8. | Очты, очты | Аз хәрәкәтле | 5-6 яшь (зурлар төркеме) | Шогыльләрдә физкультминутка буларак куллану | Алда өйрәнелгән предметларның исемнәрен искә төшерү | Ел дәвамында |
| 9. | Түбәтәй | Җырлы биюле | 6-7 яшь (мәктәпкә әзерлек төркеме) | Татар бию көенә биергә өйрәтү һәм уендагы сүзләрне кабатлау | Мөстәкыйльбию | Март апрель |
| 10 | Ал кирәк гөл кирәк. | Ярыш | 6-7 яшь (мәктәпкә әзерлек төркеме) | Уен барышында сүзләрне рольләргә бүлеп өйрәнү | Балалар уеннарны үзләре башкаралар | Июнь, июль Ачык һавада |





***Йөзек салыш***

***Төенчек***



**Чума үрдәк, чума каз**

**Сукыр тәкә**





**Түбәтәй**

# Зәңгәр чәчәк




Юл читендә зәңгәр чәчәк
Якты нурлар тарата.
Безнең кызлар һәм малайлар
Зәңгәр чәчәк  ярата.

Якын дуслар арасыннан
Берсен сайлап ал әле.
Тезләнергә ипле булыр
Мендәреңне сал әле





***Без, без, без идек уены***

***Физкультминутка “Очты, очты каргалар очты...”***



**Бармак гимнастикасы**
**“Без яздык”**

**Без яздык, без яздык,**

**Безнең бармаклар талды.**

**Без хәзер ял итәбез,**

**Аннан язып китәбез**